Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге
Чыты торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

30 ноября, 2021 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлегенең Чыты торак пунктында 2021 елның 30 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 330 (өч йөз утыз).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 192 (йөз туксан ике).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 185 (йөз сиксән биш).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 7 (җиде).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2022 елда Чыты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Чыты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Чыты авыл җирлеге башлыгы С.Ә. Фәйзрахманов